РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» сентябрь 2026 ел г. Альметьевск № 1418

Әлмәт муниципаль районы
Башкарма комитетының «Педагогик
хезмәткәрләргә - Татарстан
Республикасы Әлмәт муниципаль
районы мәгариф идарәсе ведомство
буйсынуындагы муниципаль мәгариф
учреждениеләрендә эшләүче яшь
белгечләргә айлык стимул өстәмәсе
билгеләү тәртибен раслау турында»
2019 елның 4 декабрендәге 2100 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Педагогик хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык кызыксындыру өстәмәсе билгеләү турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1270 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 21 ноябрендәге 979 номерлы карары нигезендә һәм муниципаль норматив актларны гамәлдәге законнарга туры китереп,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Педагогик хезмәткәрләргә - Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы мәгариф идарәсе ведомство буйсынуындагы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче яшь белгечләргә айлык стимул өстәмәсе билгеләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 4 декабрендәге 2100 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 22 ноябрендәге 1670 номерлы, 2024 елның 26 февралендәге 731 номерлы, 2025 елның 26 августындагы 2129 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

11 пунктта «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагог хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын, мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 8 августындагы 678 номерлы карары белән» сүзләрен «Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагог хезмәткәрләре вазыйфалары номенклатурасын, мәгариф оешмалары җитәкчеләре вазыйфаларын раслау турында» Россия Федерациясе

заказ № 4553-940

Хөкүмәтенең 2022 елның 21 февралендәге 225 номерлы карары белән» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктның өченче абзацында «2 510 сум» сүзләрен «10 000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

14 пунктның дүртенче абзацында «2 510 сум» сүзләрен «10 000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктның өченче абзацында «2 510 сум» сүзләрен «10 000 сум» сүзләренә алмаштырырга;

15 пунктның дүртенче абзацында «2 510 сум» сүзләрен «10 000 сум» сүзләренә алмаштырырга.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2025 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф. Ф. Мортазинга йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов